Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Советы

КАРАР №5-2

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 12 июле

Шәһәр җирлегенең аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-4 номерлы карарын исәпкә алып, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләр тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карар кабул итә:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы советына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә:

төзелешкә рөхсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш), җирлек территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектлар файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү, җирләрне резервлау һәм җирлек чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен тартып алу, җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән килешү төзергә.

3. Карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе штп.,Ленин урамы, 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге башлыгы И.Г. Вәлиев